РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

11 апрель, 2025 ел Кукмара ш. № 301

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Кукмара районы прокурорының 2025 елның 13 мартындагы 02-08-01-2025/Прдп2-25-20920019 номерлы протестын карап, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Советының 2021 елның 19 ноябрендәге 90 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә (2021 елның 17 декабрендәге 96 номерлы, 2023 елның 27 апрелендәге 196 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 224 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Профилактик визит

3.5.1. Профилактик визит контроль үткәрелә торган затның эшчәнлек алып бару урынында инспектор тарафыннан профилактик әңгәмә рәвешендә яисә видео-конференц-элемтәдән яки «Инспектор» мобиль кушымтасы файдаланып үткәрелә.

3.5.2. Профилактик визит контроль орган башлангычы буенча (мәҗбүри профилактик визит) яисә контрольдә тотылучы зат башлангычы буенча үткәрелә.

3.5.3. Мәҗбүри профилактик визит Федераль законның 52.1 статьясында билгеләнгән очракларда үткәрелә.

3.5.4. Мәҗбүри профилактик визит контрольдә тотылучы затның аны үткәрүдән баш тартуын күздә тотмый.

3.5.5. Мәҗбүри профилактик визитны уздыру тәмамлангач, контроль чаралар өчен Федераль законның 90 статьясында каралган тәртиптә мәҗбүри профилактик визит уздыру турында акт төзелә.

3.5.6. Контрольдә тотылучы зат башлангычы белән профилактик визит аның гаризасы буенча үткәрелергә мөмкин, әгәр мондый зат кече эшмәкәрлек субъектларына карый, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешма йә дәүләт яки муниципаль учреждение икән.

3.5.7. Профилактик визит үткәрү турында карар кабул ителгән очракта, контроль (күзәтчелек) органы егерме эш көне эчендә аны үткәрү датасын контрольдә тотылучы зат белән мондый килештерүне теркәүне тәэмин итә торган теләсә нинди ысул белән килештерә.

3.5.8. Контрольдә тотылучы зат гаризасын кире алырга йә, контроль (күзәтчелек) органына, аны уздыру датасына кадәр биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итеп, профилактик визит уздырудан баш тарту җибәрергә хокуклы.

3.5.9. Контроль үткәрелә торган затка профилактик визит барышында бирелгән аңлатмалар һәм киңәшләр тәкъдим итү характерында.»;

1.2. 3 өлештәге 4.1.5 пунктының 17 абзацында «мәҗбүри таләпләрнең үтәлешен күзәтү, урынга барып тикшерү» сүзләрен «хезмәттәшлек итүдән башка контроль чаралар» сүзләренә алмаштырырга»;

1.3. 4.5.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.3. Документлар буенча тикшерү уздыру срогы ун эш көненнән артмаска тиеш. Контроль органы тарафыннан контрольдә тотыла торган затка документлар буенча тикшерү барышында карау өчен кирәкле документларны тапшыру таләпләре җибәрелгән вакыттан алып, таләптә күрсәтелгән документларны Контроль органына тапшырган вакытка кадәр, шулай ук контрольдә тотылучы зат тапшырган документлардагы хаталарны һәм (яисә) каршылыкларны ачыклау яисә бу документлардагы белешмәләрнең контроль органындагы документлардагы белешмәләргә һәм (яисә) муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда алынган белешмәләргә туры килмәве һәм кирәкле язма аңлатмаларны тапшыру таләпләре турында Контроль органы мәгълүматын контрольдә тотылучы затка җибәргән вакыттан алып чорга кадәр документлар буенча тикшерү үткәрү срогын исәпләү туктатып тора.»;

1.4. 4.5.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.5.10. Планнан тыш документар тикшерү прокуратура органнары белән килештереп кенә уздырылырга мөмкин, аны 248-ФЗ номерлы Федераль законның 57 статьясындагы 1 өлешенең 3, 4, 6, 8 пунктлары нигезендә уздыру очрагыннан тыш»

1.5. 4.9.3 пунктының икенче абзацын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев